ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.07.2024 Балык Бистәсе штп. №170пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Расларга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия составын.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының « Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында»14.12.2017ел №263пи карары үз көчен югалткан дип танырга;

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
03.07.2024 № 170пи карары
белән расланган

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә**

1.Гомуми нигезләмәләр

1.1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында (алга таба-ведомствоара комиссия) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә дә, күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 23.12.2023 №1682 карары нигезендә социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия төзелде.

1.2.Ведомствоара комиссия Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән төзелә.

1.3.Ведомствоара комиссия үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турындагы әлеге Нигезләмәгә (алга таба-Нигезләмә) таяна.

2.Ведомствоара комиссиянең функцияләре һәм вәкаләтләре

2.1.Комиссия Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге (алга таба-социаль яклау бүлеге) тәкъдим иткән гаризаларны һәм социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү турындагы документларны карый, ялгыз яшәүче гражданнарны социаль адаптацияләү программаларын раслау турында карар кабул итә.

2.2.Мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән белешмәләргә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктында күрсәтелгән хокукый актларда билгеләнгән очракларда өстәмә тикшерү уздыру зарурилыгы булганда, ведомствоара комиссия комиссия тикшерү үткәрүне билгели, аның нәтиҗәләре буенча акт рәсмиләштерә.

## 3. Ведомствоара комиссия хокуклары

Ведомствоара комиссия хокуклы:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының башка җирле үзидарә органнарыннан, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләреннән ведомствоара комиссия эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча мәгълүмат (материаллар) алырга;

Татарстан Республикасында федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан, шулай ук оешмалардан, предприятиеләрдән, учреждениеләрдән ведомствоара комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

ведомствоара комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасында федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен, шулай ук район территориясендә урнашкан предприятие, учреждение һәм оешма вәкилләрен җәлеп итәргә.

## 4.Ведомствоара комиссиянең эш тәртибе

4.1.Ведомствоара комиссия утырышлары кирәк булган саен үткәрелә.

4.2.Ведомствоара комиссия эше белән җитәкчелек итүне аның рәисе башкара. Ведомствоара комиссия рәисе булмаганда, аның урынбасары үткәрә.

4.3.Комиссия утырышы, әгәр анда ведомствоара комиссия әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы була. Ведомствоара комиссия әгъзалары аның утырышларында алыштыру хокукыннан башка катнаша. Ведомствоара комиссия әгъзасы утырышта катнаша алмаса, ул карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә алдан тапшырырга хокуклы.

Карар ведомствоара комиссия әгъзалары санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, ведомствоара комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора. Ведомствоара комиссия карары беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә, ул комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

4.4.Ведомствоара комиссия утырышында көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләрне карый һәм карар кабул итә:

социаль адаптация программасын һәм (яки) бизнес-планны раслау турында һәм гариза бирүче белән социаль контракт төзергә тәкъдим итә;

социаль адаптация программасы проектына һәм бизнес-планга үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә (конкрет тәкъдимнәр күрсәтеп);

социаль адаптация программасын гамәлгә ашыруның һәм мөрәҗәгать итүче белән сайланган эшчәнлек төренең икътисади нәтиҗәсезлеге сәбәпле социаль контракт төзүнең максатка ярашлы булмавы турында.

Ведомствоара комиссия мөрәҗәгать итүче һәм аның гаиләсе әгъзаларының социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен билгеләү

турында карар кабул итү шартларына туры килмәве турында карар кабул итәргә хокуклы.

Документларны социаль яклау территориаль органы (социаль адаптация программасы, бизнес-план) тапшырганнан соң биш эш көне тәмамланганчы, ведомствоара комиссия утырышы үткәрелә.

4.5.Ведомствоара комиссия секретаре ведомствоара комиссия утырышы беркетмәсен 2 (ике) нөсхәдә әзерләүне гамәлгә ашыра.

4.6.Ведомствоара комиссия карарына мөрәҗәгать итүче законда каралган тәртиптә шикаять бирергә мөмкин.

4.7.Ведомствоара комиссия карары дәүләт социаль ярдәмен билгеләү (билгеләүдән баш тарту) өчен нигез булып тора.

4.8.Ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итүне социаль яклау бүлеге башкара (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
03.07.2024 № 170пи карары
белән расланган

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия составы**

1. Вафина А.К. – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе;

2.Исмәгыйлов Р.Д.– Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча);

3.Җамалиева Г.И. – «Доверие-Ышаныч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең гаилә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлеге мөдире, комиссия секретаре (килешү буенча).

Комиссия әгъзалары:

4.Баһаветдинова Г.М. – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы.

5. Әхмәдиев И.М. – «Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе» ДАССОның баш табибы (килешү буенча);

6. Керженцева Г.Ф. - Балык Бистәсе районы «Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча);

7. Садиков И. М. – “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" МКУ начальнигы;

8.Фәисханов К.Ш. -Балык Бистәсе муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе финанс-икътисад бүлеге начальнигы (килешү буенча).

9. Потапова Д.Р. – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы.